ЯШЕЛ БИШЕК

ТР ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ БЕЛӘН ӘЗЕРЛӘНГӘН МАХСУС КУШЫМТА

31 ГЫЙНВАР, 2009 ел

Кемне агулыйбыз?

ЭКОЛОГИЯ АЛГА ЧЫГА

Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының еллык җыенында Премьер-министр Рөстәм Миңнеханов катнашу яңалык булмады. Ул ел да килә. Ә менә коллегиядә "ТАИФ" төркеменең генераль директоры Альберт Шиһабетдиновның зур нотык белән чыгуы үзенә күрә бер символик мәгънәгә ия иде. Безнең көннәрдә табигатьне саклау һәркем өчен мөһим бурычка әйләнә.

Экологларга теләсә нинди гигант алдына шундый таләп кую өчен төпле нигез бар. Иң башта Японияне борынгы шәһәре Киотта дөнья күргән халыкара документ – Киот протоколын искә төшерик. Ул 1997 елда Берләшкән Милләтләр Оешмасының Климатның үзгәрүе турындагы рамкалы конвенциясенә өстәмә буларак кабул ителгән иде. Аның буенча сәнәгать алга киткән барлык илләр өчен һава торышын үзгәртүче парник газларын атмосферага чыгару күләме алдан билгеләп куелырга тиеш. Киот протоколы алты төр газның һавага таралуын күзәтеп торуны мәҗбүри шарт итеп куйды. Менә шуннан соң безнең республикада да экология турындагы барлык законнарга төзәтмәләр кертелде. Хәзер бездә һәр муниципаль берәмлек, һәр предприятиенең һаваны зарарлау мөмкинлеге "Атмосфера һавасын саклау һәм аннан дөрес файдалану" законы нигезендә ачыклана.

Моны Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы белгечләре кулына әре хакимиятләрне һәм предприятиеләрне "боргычлау" өчен бирелгән бик берәгәйле күсәк дип танырга кирәк. Алдан ук әйтеп куйыйк: әлегә экологлар аннан бик тыйнак кына файдаланалар. Шулай да бу юнәлештәге эшне җитдиләндерүләре коллегия барышында сизелеп торды.

Һаваны пычрату дигәндә завод торбалары гына күздә тотылмый бит. Чүп таулары, тирес базлары, юынтык су чокырлары да һаваны бик шәп агулый. Ә төтен туздырып чабучы транспорт турында әйткән дә юк. Менә шуңа күрә министрлык үз эшен ике юнәлештә алып бара. Аның берсе пычрату чыганакларын киметү булса, икенчесе әйләнә-тирә мохитне даими күзәтеп, кимчелекләргә чара күрү. Шул рәвешле табигатьне сәламәтләндерүгә омтылу күзгә күренерлек нәтиҗәләр дә бирә. Аларны санга салып сөйләсәң дә күңелле.

Министрлык мәгълүматларына караганда, былтыр һаваны зарарлы матдәләр белән агулауны 12 мең тоннага, көнкүрештәге каты калдыкларны җир өстенә чыгарып өюне 225 мең тоннага киметүгә ирешкәннәр. Предприятиеләр продукция эшләп чыгаруны иң югары ноктага күтәргән, ә халыкның аны сарфатсыз кулланыу хәттин ашкан ел өчен зур уңыш бу. Былтыр, ниһаять, Казан каласында чүп аралау станциясенең беренчесен эшләтәп җибәрә алдылар. Хәзер икенчесен ачарга әзерләнәләр. Андый линияләрнең кечерәкләре Кукмара, Чирмешән, Азнакай, Минзәлә, Мамадыш, Арча, Лениногорск шәһәрләрендә дә хәрәкәткә килеп, алар чүп полигоннарына басымны киметү генә түгел, икенче чимал туплауга да өлеш кертәләр. Быел тагын 14 районда шундый линия корылачак икән. Татарстан Фәннәр академиясе президенты Әхмәт Мазһаров исә Татарстан шәһәрләрендә чүпне төрләргә аерып җыю вакыты килеп җиткән дип саный.

Һаваны пычратуда иң зур гаеп ияләре булган җәмәгать һәм сәнәгать транспортын да иярлекләү бара. Соңгылары әкренләп булса да газ ягуга күчерелә.

– Казан шәһәренең автобуслар паркын яңартуы һавага уңай тәэсир итте, – дигән нәтиҗә ясады министр Әгъләм Садретдинов. Узган ел экологларның 306 транспорт оешмасын тикшерүе аларда да тәртип салыныр дигән өмет тудыра.

Бу уңайдан җәмәгать транспортының гына түгел, предприятиеләр һәм шәхси транспортның да "Евро-4" бензинына күчүе өлгереп җиткән мәсьәләгә әйләнде. Түбән Кама шәһәре һәм районы хакиме Айдар Метшинның фикере шундый: "Шәһәрдә "Нефтехим", "Шина", "ТАИФ-НК" кебек предприятиеләр белән рәттән, враграк предприятиеләр дә һавага зарарлы газлар чыгаруны киметерлек технологияләргә күчәләр, жиһазларны яңарталар. Ләкин транспорт сыйфатсыз автоягулыктан котыла алмаса, халык сулар һавабызның чистартуын бик тиз генә сизмәячәк.

Табигатьне саклауга елына 9 млрд сум акча тоткан "ТАИФ" компаниясенең генераль директоры Альберт Шиһабетдиновны да борчый бу мәсьәлә. Түбән Камадагы нефть эшкәртү заводында бензин, керосин мазот җитештерүче буларак, аны ягулык базарында күмәртәләп эшләүче эшмәкәрләрнең күрше-тирәдән килүче очсызлы ягулыкка кызыгуы гаҗәпләндерә. Түбән Новгород, Башкортстан, Самара нефть эшкәртү заводларының продукциясе табигатькә зыян китермәүләрен раслауны халыкара – ИСО-1400 сертификатын ала алмаганнар. Шуңа да карамастан аларның ягулыгы безнең республикага агылып керә.

Альберт Шиһабетдинов:

– Үзебез җитештергән ике миллион тонна бензинны чит илләргә сатабыз, ә Казанның Себер тракты, Болак, Восстание урамнарында начар сыйфатлы бензин яккан автомобильләрдән чыккан соры сөрем тибрәлеп тора, – дип белдергәннән соң урамга чыгучылар Павлюхин урамында һәм Оренбург трактында да нәкъ шундый күренешкә шаһит булганнардыр.

Һәр гаилә диярлек автомобиль тоткан миллионлы Казан шәһәрендә мондый хәл озак бара алмаячак. Министр үзләренең Президент Минтимер Шәймиев кушуы буенча 2009-2015 елларга һәм 2030 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасының экологик иминлек программасын әзерләүләре турында әйтеп китте.

– Аның нигезенә әйләнәтирә мохитне, беренче чиратта атмосфера һавасын саныктыру чаралары салыначак, – диде Әгъләм Садретдинов. – Агымдагы елда ук зарарлы газларны һавага чыгару 2 процентка кимергә тиеш.

Ә бу җәмгыесы 7 мең тонна углеводород окисе, метан, азот окисе, гидрофторуглерод, күкерт гексофториды безне агулаудан туктаячак дигән сүз. Бүгенге көндә автоматлаштырылган 12 стационар пункт Казан, Түбән Кама, Чаллы, Әлмәт, Алабуга, Азнакай шәһәрләре һавасын тикшереп, Экология министрлыгының башкалада урнашкан заманча лаборатория комплексына мәгълүматлар тапшырып тора. Күченеп йөрүче станцияләр дә бар. Быел тагын республикада 7 стационар пост һәм берничә күчмә станция сатып алып, Татарстанның төрле төбәкләренә урнаштырылачак. Министр:

– Экологик мониторинг гадел ясалсын һәм халык чын дөреслекне белсен өчен 35 постны эченә алган челтәр булдыру өстендә эшлибез, – дип белдерә икән, республикада бер генә пычрату чыганагы да әлегә күзәтүдән читтә кала алмаячак дигән өмет туа.

Табигать турында чын дөреслекне приборлар ярдәмендә ачыкларга буладыр да ул. Тик менә әйләнә-тирә-безгә салынган җәбер-җәфаны киметү өчен үз күңелебездәге битарафлык, шаккылык, комсызлык, инсафсызлык кебек сыйфатлардан ничек котылырга? Галимнәр табигать баласы – адәм күңелендәге андый золымны үлчәү җайланмалары уйлап чыгармаганнар шул әле. Шуңа күрә Премьер-министр Рөстәм Миңнеханов та коллегиядә катнашучыларны намуслылыкка өндәү белән генә чикләнде.

– Европача яшәргә телибез икән, табигать турында да Европадагы кебек кайгыртырга кирәк, – диде ул. Нигә Лондон ямь-яшел парклардан тора, ни өчен Минскида паркларның исәбе-хисабы юк. Агач утыртмыйча, чүпчарыбызны җыймыйча, чиста ягулыкка күчмичә, без кемне алдыйбыз соң? Табигатьне дип уйлыйсызмы? Юк! Фәкать үз-үзебезне!

Илсөяр ХӘЙРУЛЛИНА

КАЙТАВАЗ

"Җир ярасын кем ямар?"

("ВТ".06.12.2008)

Шушы исемдәге баш белән дөнья күргән мәкаләгә авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары И.Габдрахманов имзалаган русча хат алынды. Анда түбәндәгеләр хәбәр ителә: "Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан туфракның уңдырышлы катламы юылу, иген кырларында ерганаклар барлыкка килүне азайту максатыннан эзлекле эш алып барыла. 1997-2003 елларда сөзәклеге 5 градустан арткан 225 мең гектар сөрү җире чәчү әйләнешеннән чыгарылды. Анда хәзер терлек азыгы культуралары чәчелә.

Республикада авыл хуҗалыгы культураларын туфракка зыян салмаслык итеп үстерү технологияләре кертелә. Җир өске катламны әйләндереп салмыйча эшкәртелә. Авыл хуҗалыгы культуралары басуларга турыдан-туры чәчелә. Ә саламны ваклап җир өстенә тарату аның су һәм җир тәэсирендә ярганлануын азайта. 1,6-1,7 миллион гектар чәчүлек җире шундый алым белән эшкәртелә. Бу барлык мәйданның 65 проценты дигән сүз.

Республикада ерганакларның артуын киметүгә каршы аларны әйләндереп агач утырту, тау битләрен дә рәт-рәт ызанлап урманнар үстерү юлы белән көрәшәбез. Бу максат өчен 2008 елда 157 миллион сум акча тотылган. Шуның бәрабәренә 2864 гектарда эрозиягә каршы урман полосалары, 735 гектардагы тау битләрендә урманнар утыртылган.

Республиканың "2008-2012 елларга Татарстанда авыл хуҗалыгын үстерү" максатчан программасында туфракның уңдырышлылыгын күтәрү, аның составын яхшырту өчен 4,6 миллиард сум акча бүлеп бирү каралган".

P.S."Җир ярасын кем ямар?" мәкаләсендә төп сүз җирләрне беренчел сыйфатлы хәленә кайтару өчен иң башта анда тикшеренү эшләре үткәрү һәм аларның картасын булдыру турында сүз барган иде. Министрлыкта әллә язманың эчтәлеген аңламаганнар, әллә аны тулысынча укып чыгарга түземлекләре җитмәгән.

Д.Бунтуков

Приборны алдап булмый

ЯҢАЛЫК ӘЗЕННӘН

Әлмәт предприятиеләре бүген гөрләп эшли. Илдә барган кризис та безгә комачау итә алмый, ди биредәгеләр.

Һава составын ачыклау постының берсе Экология министрлыгының үз бинасы янына урнашкан

Нефть кудыру белән шөгыльләнүче "Калейкино" станциясе хезмәткәрләре Казаннан килгән журналистларны: "Әлегә кадрларны кыскарту юк",– дип ышандырырга тырыштылар. Табигатькә дә мөнәсәбәт сак икән монда. Тик: "Аккан җирдә тама", – ди халык. Менә шуны булдырмас өчен, элекке металл торбалар металлпластмастан ясалганнары белән алмаштырылган. Тимер һәм бетон материалларыннан ясалган 12 нефть саклагыч сүтелеп, алар урынына 50 мең куб метр сыйдырышлы яңа төрләләре корылган. Экологик яктан куркынычсыз мондый дәү саклагычлар әлегә АКШта һәм Венесуэлада гына бар икән. Өсләре каплаулы булган һәм углеводородның җиңел фракцияләрен җыя торган җиһазлар урнаштырылган ул гигант чаннардан һавага чыга торган зарарлы матдәләр күләме күп тапкырларга кими, дип раслый белгечләр.

– Соңгы елларда Әлмәт шәһәренең табигатен савыктыру өчен бик күп эшләнде,– дип раслый экология һәм табигый ресурслар министры Әгъләм Садретдинов. – "Татнефть" җәмгыяте экология өчен акча кызганмый. 2008 елда гына да ул бу максатка 5 миллиард сум акча салды.

Әмма бу – нефть компаниясе һәм нефть төбәгендә урнашкан башка предприятиеләрнең эшчәнлеген бүтән тикшереп торырга кирәк түгел дигәнне аңлатмый. Киресенчә, табигатьне яклау көчәя генә бара. Моның өчен, заманча ысулларга таяналар. Республикада һавага чыга торган зарарлы матдәләрне ачыклап, әлегә күренешне даими күзәтү өчен мониторинг челтәрен булдыру программасы кабул ителде. Министр һәм экология белгечләренең Әлмәт якларына килеп чыгуы да шуңа бәйле. Түбән Мактама бистәсендә атмосфераны күзәтеп тору пункты ачылды. Биредә "Миңнебай" газ эшкәртү заводы, "Газпром-Казан"ның Әлмәт идарәсе, Әлмәтавтодор һәм башка сәнәгать предприятиеләре урнашканлыктан, һаваны агулаучы зарарлы матдәләр күләмен ачыклау һәм чаралар күрү бик мөһим. Министрның әйтүенә караганда, Әлмәттә тагын шундый бер пункт булдырылачак. 4,5 миллион сумлык әлегә җайланма көне-төне һава сагында тора. Ул 20 минут саен автомат рәвештә һава торышы турындагы мәгълүматны Казандагы үзәккә җиткереп торачак. Мәгълүматны ул 40 тәүлек үз хәтерендә саклый.

Бүген республикада Экология министрлыгы тарафыннан шундый 12 станция урнаштырылган. Аларның дүртесе – Казанда, өчесе – Түбән Камада, икесе – Чаллыда, калганнары Алабуга, Азнакай, Әлмәт шәһәрләрендә. Мониторинг челтәрләре шундый 36 станциядән торачак. Болар өстенә тагын 10 күчмә станция булдыру күздә тотыла.

Мондый чара нефть төбәгендәге предприятиеләр белән халык арасындагы экология буенча кызгала торган бәхәсләргә нокта куячак.

Чулпан ХӘЙРУЛЛИНА

"ТАТНЕФТЬ" АТМОСФЕРАНЫ САКЛАУ ӨЧЕН НӘРСӘ ЭШЛИ?

– Технология җайланмаларының торышын тиешле дәрәҗәдә тота;

– Нефть саклагыч парк җайланмаларын углеводородның җиңел фракцияләрен тотып алучы җиһазлар белән тәэмин итә. Аларны куллана башлаганнан бирле һавага чыга торган углеводород күләмен дүрт тапкырга кадәр киметергә мөмкин булган. Бүген шундый 42 җайланма сафта тора. Тотып алынган углеводород күләме бер миллион тоннадан артып киткән.

– Нефть табуда кулланыла торган транспортны газ ягулыгына күчерә.

– Машина юллары тирәләрен яшеллек белән бизи. Барлыгы 300 мең агач утырткан.

Нәтиҗәдә: 2006 елдан алып торак пунктлар һавасында сероводород катнашмасының артуы сизелми.

"Татнефть"тә каршылык юк

Бәйсез Экологик Рейтинг агентлыгы (НЭРА) тарафыннан экологик каршылыкка керүче предприятиеләрнең рейтинг исемлеге төзелгән. Анда беренче урыннар бу мәсьәләдә иң начарлар рәтенә кертелгән компанияләргә бирелгән. Ә экология белән чын-чыннан шөгыльләнүче нефть предприятиеләре анда бөтенләй телгә алынмый. "Татнефть" ачык акционерлык җәмгыятенең бу рейтингта булмавы аларның экологик тәртип бозулардан азат булуы хакында сөйли.

2008 елда халыктан турыдан-туры (он-лайн) сораштыру нәтиҗәсендә әлегә чарада катнашучыларның 430 ы әйләнә-тирә мохиткә зарар салу күренешләре белән таныш булулары турында хәбәр иткән. Табигать белән каршылыкка керүчеләрнең исемлеген "Роснефть" житәкли. Әлегә предприятие турында халыктан алынган тискәре мәгълүмат бер ел эчендә 14 тән 39 га кадәр күтәрелгән. "Транснефть" составына керүче предприятиеләр 2008 елда элеккеге 10 урынына 47 экологик тәртип бозучы буларак телгә алына. Алардан "Газпром" вәкилләре дә катнашмый. Узган ел мәгълүмат чаралары аларда 9 экологик тәртип бозу турында хәбәр итте.

Экологик Рейтинг агентлыгының бу чарасында 69 компания катнаша. Аларның 50 сен "начарлар" исемлегенә тезеп чыгалар. Ә табигать белән экологик каршылыкка кермәгән компанияләр анда урын алмый. 2008 ел нәтиҗәләре буенча бу исемлеккә "Татнефть", "Татэнерго", "Көнбатыш Себер металлургия комбинаты", "ЛУКОЙЛ", "Сургутнефтегаз" кебек предприятиеләр кермәгән.

"Сарман буйларында яшел алан..."

Ерак гасырлардан килгән шушы җырны кемнәр ишетмәгән дә кемнәр генә аны көйләп сагыш-кайгысын басмаган? Борынгы ата-бабаларыбыз туган җирнең матурлыгына сокланып, аңа багышлап чыгарган мәңгелек "Сарман" җыры бит ул! Бүген дә оныталмый, халык теленнән төшми торган моңлы көй. Чыннан да, бик ямьле, гүзәл шул Сарман яклары.

Мондагы яшел болынларны тамаша кылып, салкын чишмә суларын эчеп, елга-күлләрендә ял итеп, коеныр туймаслык. Менә шулай рәхәт чиккәндә шушы гүзәл табигать, әйләнә-тирә мохит сагында торучы алтын куллы кешеләрне рәхмәт хисләре белән искә төшереп, алар хезмәтен һәрвакыт кадерләсәк, бәрәкәтле тотсак икән!

"Җәлилнефть" идарәсе коллективы башкарган игелекле, нәтиҗәле эшләр белән танышып йөргәндә уйландым бу хакта. Табигатьне саклау һәм эрозиягә каршы көрәш бүлеге житәкчесе урынбасары Әдип Мотыйгуллин белән күбрәк елга-күлләрнең арулыгы турында гәп кордык. Берничә муниципаль район биләмәсендә эшләүче нефтьчеләр 80 ләп чишмәне чистартып, тирәягын зәвыклы итеп төзекләндергәннәр. Берсеннән-берсе ямьлерәк, тавышлырак челтерәвек, салкын сулы кабатланмас, үзенчәлекле чишмәләр... Исемнәре генә дә ни тора! "Тырыш", "Культура", "Парлы чишмә", "Туган авыл"... Әлмәт районындагы ул "Туган авыл" атлысын чагыштырмача яңа гына эзгә төшереп, көйләп җибәргәннәр. Салкын чишмә авылының күркенә, горурлыгына әверелгән ул хәзер.

"Тырыш" дигәнен нефть һәм газ чыгару идарәсенең яшьләр оешмасы төзекләндереп, яңартып биргән. Чишмә янындагы күрсәтмә тактасы әлегә егет-кызларның эшен мактаудан битәр, аларның бүтән яшьтәшләренә адресланган "шулардан үрнәк алыгыз, туган җирне кадерләгез, саклагыз" дигән ишарә-киная хезмәтен үти сыман. Ә нәрсә, шулай була калганда да артык түгел. Югыйсә әлегә көмеш су чыганагының табигать кочагында кәеф-сафа корырга яраткан кайбер имансыз адәмнәрнең тупаслыгына, ватау-жимерүенә дучар булганы бар икән. Дөрес, тиешле гадел җәзасын да алганнар үзләре.

Чишмәләр генә түгел, инеш-елгалар, күлләр дә шул рәвешле уяу саклауга мохтаж, әлбәттә. Табигать кәйсезлегенә каршы ашыгыч чаралар күрергә дә туры килә. "Кара алтын" кеше кушкан төшкә торбалар буенча гына йөгерми шул, җир өстенә, суга аккан-тамган чаклары да булгалый. Аеруча язгы ташулар чорында су нефть калдыклары белән пычранырга, зararланырга мөмкин. Моннан котылу юлын тапканнар, шөкер. Елга агымы уңаена мазутынмазарын тотып калучы махсус экология җайланмасы куелган. Эреле-ваклы елга-инешләрдәге 100гә якын урында кәйләнгән "капкын" дип аталучы шушы корылма. Ык суына коя торган Мәлләелгасындагы ул искиткеч корылма табигать аерата нык саклана торган зонада урнашкан. Мөлаем кеше инженер Фәндәс Җамалиев күрсәтеп йөрде аны безгә. Рантамак авылы янында урнашкан әлегә плотина төзелешен ифрат жанланып, дәртләнеп аңлатты нефть чыгару ветераны. Күренеп тора, аны углевод, чимал күләме, аннан керәсе табыш кына кызыксындырмый, табигать чисталыгы, әйләнә-тирә мохит өчен дә жан атып йөри ул. Кесә ягын гына кайгыртмаучы андый нефтьчеләр күбрәк булсын иде дип уйламый хәлең юк. Ә теге урысча "ловушка" дигәне гади генә нәрсәгә, нефтьнең авырлыгы судан кимрәк булуына исәпләп төзелгән икән. Ул торбалар чиста суны үткәрә, ә карамай элпәсен тотып кала. Ә нәтиҗәсе? Нәтиҗәсен шунда ук үзебез күреп инандык: балыкчы кармакны салып кына тора, карыш буйлы "көмеш тәнле" балык яр буенда ялтырап килеп төшә. Язгы ташулар вакытында әшәке суларга аеруча ышанычлы киртә салынган монда. Биредән Ык елгасына фәкать саф, ару агым гына кушыла дип ышандыралар. Башка төшләрдә дә шулай. Чөнки идарәдә әлегә корылмалардан көзге-кышкы чорда файдалануга әзерлек буенча конкурс оештырыла. Ә ул бәйге исә көн саен елгаларда күзәтү алып баруны, ул-бу чыга калса, җәһәт кенә чара күрүне күздә тота. Табигать караучысыз түгел, аның халәте, хәле ныклы контрольдә, күз уңында тора, димәк.

Илдус ДИНДАРОВ.
Сарман районы